Мәкаләдә «Безнең мирас» журналының басыла башлау һәм нәшер ителү тарихы белән бәйле материал яктыртыла. «Мирас»ның беренче номеры 1991 елда дөнья күрә. Ф.Мусин, Ә.Сәхапов, И.Ибраһимов, Л.Лероннар – әлеге басманың төрле еллардагы баш мөхәррирләре. Журналның фәнни концепциясен формалаштыруда Ә.Еники, Г.Бәширов, М.Мәһдиев, М.Госманов, Ә.Кәримуллин, М.Мәхмүтов кебек күренекле татар галимнәре, язучылар һәм җәмәгать эшлеклеләре катнаша. Хезмәттә журналның тарихи-документаль мирасны, татар халкының милли хәзинәсе булган башка тарихи-мәдәни кыйммәтләрне саклауга һәм арттыруга йөз тоткан контенты буенча аларның тәкъдимнәре теркәлгән чыганакларга, язмаларның актив һәм киңкырлы кулланылышына күзәтү ясала. Басма рубрикаларының яңарып торуы, журналның чирек гасыр дәвамындагы төп үсеш тенденцияләре билгеләнә. Мәкалә авторлары журналның татар халкы тарихы белән кызыксынган Россия һәм чит ил укучыларының киң катламына, шул ук вакытта татар халкы тарихы, әдәбияты, теле һәм мәдәнияте өлкәләренә караган фундаменталь комплекслы тикшеренүләре нәтиҗәләрен әлеге басма битләрендә нәшер итү мөмкинлекләренә ия булган махсус белгечләргә дә йөз тотуын ассызыклыйлар. Журналның гомумтарихи, патриотик тематикасын фәнни-популяр мәкаләләре белән тәэмин итүдә педагогик эшчәнлек алып баручы, тарихны, туган якны өйрәнү белән шөгыльләнүче укучыларның өлеше кыскача бәяләнә. Мәкаләдә «Безнең мирас» басмасының бүгенгесе һәм киләчәккә планнары хакында күзаллауларга мөмкинлек бирә торган статистик мәгълүматлар да китерелә.

**Төп төшенчәләр**: татар журналистикасы тарихы, «Безнең мирас» журналы, басылу тарихы, рубрикалар, таралу географиясе.

1991 елда – Татарстан Республикасы өчен гаять әһәмиятле һәм катлаулы чорда – күренекле галимнәрнең, үткәнебезгә битараф булмаган зыялыларның, бихисап әһле каләмнәрнең тырышлыгы белән татар халкының күпгасырлык мирасын киң катлам җәмәгатьчелеккә җиткерергә алынган «Мирас» журналының чыга башлавы зур тарихи-мәдәни вакыйга булды.

Әмирхан Еники, Гомәр Бәширов, Мөхәммәт Мәһдиев, Миркасыйм Госманов, Әбрар Кәримуллин, Мирза Мәхмүтов кебек дистәләгән олуг әдипләр һәм галимнәр фатихасы белән барлыкка килгән бу басма хәзерге вакытка кадәр үзенчәлекле һәм озын юл үтте: күпне кичергән халкыбызга рухи таяныч, җан азыгы булып, төрле кыйтгаларга сибелгән милләттәшләребезне барлауда, аларны берләштерүдә, тарихка ихтирамлы объектив караш тәрбияләүдә зур роль уйнады; җөмһүриятебез белән бергә журнал да, җитди үсеш кичереп, татар укучысының яраткан басмасына әйләнде.

Билгеле булганча, «Мирас» журналын нәшер итү, аның басма хасияте, фәнни концепциясе кебек мәсьәләләр җитди сөйләшүләрнең һәм фикер алышуларның үзәгендә була. Халык язучысы Ә.Еники «Мирас» журналын нәшер итүгә татар халкының күпгасырлык әдәби-мәдәни мирасын, рухи байлыгын саклау ноктасыннан якын килә: « “Мирас! ” Күптән кирәклеген сизә идек, күптән көтә идек. Мирасыбыз таркау, җыелмаган, каралмаган… Хәер, бөтенләй үк

игьтибар итмәдек, дип әйтә алмыйбыз. Мираска багышланган аерым хезмәтләр һаман чыга торды, шуларның иң зурысы – татар халык иҗатын җыйган томнар. Ләкин мирас ул – тирән катлаулы байлык, аның күз төшмәгән, кул җитмәгән катламнары бик күп. Шул ук вакытта мирас ул – һаман өстәлә бара торган байлык та. Әйтик, совет дәверендә чыккан нәрсәләр дә хәзер мираска әйләнде.

Менә шушы гасырлар дәвамында җыела килгән мирасыбызны күздән кичерү, онытылганнарын табу, тикшерү, ниһаять, дөньяга чыгара бару өчен, әлбәттә, даими бер журналыбыз булырга тиеш иде. Мин монда кайсы дәвер, нинди мирасларга игътибарны юнәлтү кирәклегенә тукталып тормыйм. Барысы да кирәк, берсен дә игътибарсыз калдырырга ярамый. Билгеле, "Мирас"ның эше күп тә, бик кызыклы да булачак. Һәм халкыбызның аң, белем, культура дәрәҗәсен күтәрүдә дә ул, һичшиксез, зур роль уйнаячак.» [1: 3]

Татар халкының язма истәлекләре тупланып, фәнни яктан анализланган дистәләгән хезмәтләр авторы, текстолог, тарихчы галим академик М.Госманов басманың рубрикаларын ачыклый һәм журнал эчтәлегенең төп өлешен язма мирас истәлекләре билгеләргә тиеш дигән фикердә тора: «Журналның төп эчтәлеген, әлбәттә, иң элек язма мирасыбыз истәлекләре тәшкил итәргә тиеш. Бу – бәхәссез. Шулай ук анда "Халык иҗаты ядкарьләре" дигән бүлекнең булуы да акланган…

Әлбәттә, матди мәдәниятебез, бигрәк тә нәфис һәм гамәли сәнгатебез истәлекләрен барлау, теркәү, гыйльми тасвирлау һәм пропагандалауны да төп бурыч иткән махсус бүлекне дә даими күрәсе килә… Җыеп әйткәндә, яңа журнал алдында мин өч төрле мөһим һәм гаять авыр бурыч күрәм:

1) гамәлдә мөстәкыйльлек һәм фикердә хөрлеккә омтылу;

2) эчтәлектә киңлек, ягъни чын рухи байлыкка таяну;

3) эштә сыйфатка, димәк, тынгысыз хезмәткә алыну» [1: 4-5] .

«Мирас» журналын чыгаруның мөһимлеге хакындагы сөйләшүгә Татарстанның халык язучысы М.Мәһдиев тә кушылып, үз карашын төрки-татар халыкларының мәңгелек юлдашы булган ат турындагы әйтем белән ныгыта: «Француз язучысы Гюстав Флоберның "Хакыйкать лексиконы" исемле сүзлегендә ат турында болай диелә: "Ат, әгәр дә үзендә күпме көч барын белсә, үзен йөгәнләргә, йөгәндә йөртергә мөмкинлек бирмәс иде".

Татар халкы да, үзенең тарихында күпме этик, эстетик, әхлакый байлык тупланганын белмичә, гасырлар кичерә. Бу байлыкны оныттырыр өчен империячел сәясәт, большевизм идеологиясе байтак көч сарыф итте. "Мирас" журналының битләрендә мин әнә шул күмелеп яткан байлыгыбызның дөнья күрүен телəр идем» [1: 5]

Фикер алышуда «Мирас» журналы эчтәлегенең төрле аспектлары тикшерелә. Татар әдәбиятының классигы Г.Бәширов басма битләрендә экология мирасын, эпиграфика тармаклары һәм аның кыйммәтле мәсьәләләрен дә яктыртуны күтәреп, сөйләшү тематикасын тагын да киңәйтеп җибәрә: «Мирасның матбугатта бик сирәк телгә алына торган янә бер тармагы бар. Ул – эпиграфика. Борынгы кабер ташлары тел, орнамент һәм әдәбият элементларын саклап калулары белән тарихны өйрәнүдә зур урын тоталар, һәркайсыбызга мәгълүм, Татарстан җирендә һәм күрше өлкәләрдә Болгар һәм Казан ханлыгы чорыннан калган кабер ташлары шактый күп…

Әгәр дә "Мирас" журналы бабаларыбыздан калган бу биниһая кадерле һәйкәлләрне игътибар үзәгенә алып, аларны саклау кирәклеген укучыларына бөтен кискенлеге белән төшендерә барса, бик тә изге бер эш башкарылган булыр иде…» [2: 3-4].

Югары мәдәнилекнең күрсәткечләреннән берсе – китап, китапчылык белеме тармагының зур белгече, библиограф, филолог Ә.Кәримуллин карашынча, татар халкы өчен бу журналның чыга башлавы аерата кадерле һәм кирәк. Кыска вакыт эчендә тел графикасын ике тапкыр көчләп алыштыру аркасында, бай мәдәни, фәнни, әдәби мирастан халык аерыла. Мирасыннан аерылган халыкның киләчәге шикле. Әдәби мирас ул – халыкның рухы, җаны, дөньяны тану формасы, үткән гасырларның тәҗрибәсе, табышы һәм ачышлары, киңәш һәм уйланулары, уй һәм фикерләре, хыял һәм теләкләре, киләчәк буыннарга васыяте. Рухи мирасыннан аерылган халык – чиксез далада адашкан, кыйбласыз халык ул. Моның нәрсәгә китергәне совет чорында ачык күренде [3: 5].

Халык мәгарифе эшлеклесе, педагог, күптөрле яңа методик проектлар авторы, академик М.Мәхмүтов «Мирас» журналының мәгънәви кыйммәтен халкыбызның

гасырлардан-гасырларга, буыннан-буынга күчеп килгән акыл егәрлеген, азатлык рухын, милли хосусиятләрен халыкның үзенә кире кайтару һәм саклау ноктасыннан бәяли: «Мирас ул – буыннан-буынга күчеп килә торган байлык. Матди байлык ул – фани, бетә торган, вакытлы нәрсә, ә рухи байлык, фикер байлыгы, акыл көче белән хасил булган дөньяга караш, кешеләрнең үзара инсафка нигезләнгән мөгамәләсе, гореф-гадәте – бакый, мәңгелек. Мирасның иң кадерлесе – халыкта сакланып килгән азатлык рухы, хөррият хыялы.

Андый мирас аерым шәхестә булмаса да, бербөтен халыкның гомуми җанына сеңеп кала, аның телендә, әдәбиятында, иҗатында, әдәп-тәртибендә, гореф-гадәтендә, фикерләү сәләтендә, буыннан-буынга күчеп килгән риваятьләрендә саклана. Азатлыкка, читлектәге кош кебек канат кагып иреккә чыгарга омтылу – татарларга ата-бабадан калган мирас ул. Һәртөрле золымга булган күңел каршылыгы ачы сүзләр булып бүген мәйданнардан күккә күтәрелә… Бай мирасыбызны өйрәнеп, үстереп киләчәк буыннарга түкми-чәчмичә генә тапшырасы иде. “Мирас” журналы нәкъ менә халкыбызның тарихи, рухи байлыгын саклап калу, аны халыкка яңадан кайтару өчен кирәк.» [3: 5].

Шулай итеп, «Мирас» журналы татар халкы «азатлыкка, читлектәге кош кебек канат кагып иреккә чыгарга омтылган» чорда дөньяга аваз сала. Бу хакта басманы оештыруга күп көч куйган фидакяр шәхес – «Мирас»ның беренче баш мөхәррире, күренекле галим, язучы Ф.Мусин фикерләре аеруча игътибарга лаек. Ул үз язмасында беркадәр алгарак китеп, журналны нәшер итүгә әзерләгән мөһим вакыйгаларга, мәдәни фактларга күзәтү ясый. Галим 1987 елның 10 ноябрендә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында (хәзерге Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты. – *Ф.З.*) «Татар халкының күпгасырлык рухи мирасын туплау, өйрәнү һәм пропагандалау белән шөгыльләнүче комиссия» төзелүе турында яза. Әлеге комиссиянең, бай тарихыбызның һәм мирасыбызның моңа кадәр күтәрелмәгән бик мөһим мәсьәләләренә багышланган дистәдән артык киңәйтелгән утырышлар үткәреп, аларга мөнәсәбәттә үзгәреш-яңарыш рухын көчәйтеп җибәрергә булышуын ассызыклый. Мондый оешманың статусын күтәрү кирәклеге дә сизелгәч, «Татар Мирас фонды» оешуын һәм аның уставы Татарстан Министрлар Советының 1991 ел, 29 гыйнвар карары белән теркәлүен әйтә. «Бер үк вакытта, халкыбызның күп гасырлык тарихындагы һәм мирасындагы “ак тап”ларны бетерү теләгебез сүздә генә калмасын өчен, махсус матбугат органын булдыру фикеренә килдек һәм “Мирас” журналын оештырдык. Аның сынау саны 1991 елның 17 августында дөнья күрде. Әйтергә кирәк, сынау санын типографиядә бастыруның ГКЧП көннәренә туры килүе чын мәгънәсендә милли рухтагы бу басманың дөньяга чыгуын куркыныч астына куйган иде. Мондый куркыныч тууының төп сәбәпләреннән берсе әлеге санда Г.Исхакыйның бездәге идеологиягә чит булган “Олуг Мөхәммәд” тарихи драмасы басылуы белән бәйләнгән иде. Мөһим башлангыч харап булмасын өчен, җаваплылыкны редакция үз өстенә алды»[4: 14-15].

Күренә ки, журналның иң тәүге саны ил, милләт язмышы өчен бик хәвефле көннәрдә баш мөхәррирнең һәм редакция хезмәткәрләренең зур кыюлыгы белән нәшер ителә. «Мирас»ның чыга башлавы татар халкының мәдәни тормышында әһәмиятле вакыйга була. Бердән, ниһаять, киң җәмәгатьчелеккә аз билгеле булган мәдәни-тарихи һәм рухи мирасыбызның үз матбугат органы барлыкка килә. Икенчедән, яңа журнал иҗтимагый-сәяси, мәдәни, рухи үткәнебезне фәнни өйрәнү һәм пропагандалау эшенә яңа рух өрер, аны тагын да активлаштырыр дигән ышаныч туа. Моның өчен журнал тирәсенә әлеге мәсьәләләр белән шөгыльләнүче яки кызыксынучы белгечләрне һәм киң җәмәгатьчелекне туплау күздә тотыла. Өченчедән, журнал милләттәшләребезнең тарихи үткәнебез белән кызыксынуын тагын да көчәйтүгә булышыр дип уйланыла. Журнал шул ук вакытта халкыбыз тарихы белән мирасның зурлыгын һәм байлыгын да күрсәтә торган фактор да була. Дүртенчедән, иң әһәмиятлесе – бу татар халкының азатлык-хөрлеккә сусаган, мәйданнарда мөстәкыйльлеккә, ахыр чиктә милли дәүләтчелегебезне торгызуга омтылыш рухы хөкем сөргән, милли үзаң уяна башлаган чор була.

«Мирас»ның 1991 елгы сынау санындагы кереш сүзендә журнал эшчәнлегенең төп баганалары яки юнәлешләре рәвешендә үткәндәге әдәби-сәнгати, иҗтимагый-фәлсәфи, әхлакый һәм дини мирас, халык иҗаты һәм

медицинасы ядкәрләрен хәзерге укучыларга җиткерү, халык тарихындагы «ак таплар»ны, өйрәнелмәгән мәсьәләләрне яктырту санала. Иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни үткәнебезне активрак һәм дөресрәк яктырту белән журнал халкыбызның милли үзаңын һәм горурлыгын үстерүгә хезмәт итәчәк, ягъни заманның мөһим иҗтимагый-әхлакый бурычларын тормышка ашырачак дигән өмет белдерелә.

Татар халкының күпгасырлык гражданлык һәм мәдәни тарихын яктырту аша башка милләт вәкилләрендә аңа дөрес, гадел караш тәрбияләү һәм шул нигездә республикада милләтара мөнәсәбәтләрнең тотрыклылануына ирешү дә күз алдында тотыла. Икенче яктан, «Мирас» үз чаралары белән милләтебез һәм республикабыз алдында торган гаять мөһим бурычны – Татарстанның мөстәкыйльлеге турындагы Декларацияне гамәлгә ашыруга хезмәт итәчәк. Халкыбызның тарихта эзле булуын активрак һәм нәтиҗәлерәк күрсәтүе белән ул, һичшиксез, милли үзаңның, горурлыкның үсүенә булышачак, шул нигездә милләттәшләребезне республиканың дәүләт мөстәкыйльлеге өчен көрәшкә туплауда катнашачак дигән ышаныч белдерелә [5: 4-5].

Журналның тиз арада тернәкләнеп китеп, укучылар арасында ихтирам һәм мәхәббәт казануында Мансур Хәсәнов, Әбрар Кәримуллин, Һәнүз Мәхмүдов, Альфред Халиков, Хатыйп Миңнегулов, Индус Таһиров, Нурмөхәммәт Хисамов, Марсель Әхмәтҗанов, Равил Әмирхан, Рифкат Әхмәтҗанов, Тәлгат Галиуллин, Искәндәр Измайлов, Равил Фәхретдинов, Сәлим Алишев, Мирфатыйх Зәкиев, Хуҗиәхмәт Мәхмүтов, Дамир Исхаков, Фатих Урманче, Әнвәр Хәйри, Рәшит Ягъфәров, Марсель Бакиров, Әхмәт Сәхапов, Диләрә Тумашева, Фирдәүс Гарипова кебек күпсанлы галимнәрнең, Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиев, Мөсәгыйт Хәбибуллин, Дамир Гарифуллин, Шамил Маннапов, Фирдәвес Зариф кебек бихисап язучыларыбызның, Рушан Шәмсетдинов, Зөфәр Хәкимов кебек рәссамнарыбызның өлеше зур булды. Галимә Лена Гайнанова Гаяз Исхакый әсәрләрен эзерләүдә, аларны журналда бастыруда аеруча зур көч куйды. Ул чорда редакция Татар иҗтимагый үзәге рәисе Марат Мөлековның да теләктәшлеген даими тоеп эшләде.

Гаяз Исхакый әсәрләре, борынгы мирас ядкярләре әүвәл укучыларга «Мирас» журналы аша барып иреште. Ул елларда басма укытучылар һәм укучылар, студентлар өчен уку ярдәмлеге вазифасын үтәп килде. «Мирас» журналы РФ Югары аттестация комиссиясенең фәнни басмалары исемлегенә кертелде. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: фәннилек принцибын саклаган хәлдә, журналдагы хезмәтләр һәм әсәрләр халыкка аңлаешлы телдә бирелеп килде. Басмада түбәндәге сәхифәләр даими эшләп килә: «Бөек Болгар дәүләте тарихы», «Татар халкының милли азатлык хәрәкәте», «Татар энциклопедиясе», «Әдәби мирас һәм сәнгать», «Дин һәм әхлак», «Татарстан мәмләкәте», «Татар диаспорасы», «Дини мирас», «Ислам мәдәнияте», «Ислам фәлсәфәсе», «Авыллар тарихы», «Фикерләр дөньясында», «Хокукый мирас», «Татар этногенезы», «Милли мәгариф» «Халык иҗаты», «Шигърият», «Тарихи мирас», «Сәяси мирас», «Археологик мирас», «Сәнгать белеме мирасы», «Борынгы бабаларыбыз тарихы», «Алтын Урда тарихы», «Казан ханлыгы тарихы», «Төрки халыклар дөньясы», «Мирас» энциклопедиясе, «Мирас» почтасы» [6: 193].

Мәгълүм сәбәпләр аркасында, 1992 елда баш мөхәррир вазифасы Әхмәт Сәхаповка йөкләнә. 2012 елда журнал исеме үзгәртелеп, «Чын мирас» атамасы белән чыга башлады. Басманың ул вакыттагы баш мөхәррире Илфак Ибраһимов билгеләп үткәнчә: «Журналның “Чын мирас” булып теркәлүендә аның булачак редакторының да, авторларының да катнашы юк иде. Мирас чын булмыйча, ялган булмас» [7: 62].

Күренекле галим, язучы һәм тәрҗемәче Л.Хәмидуллин «Уңышлы башламнар» дигән мәкаләсендә, «Татарстан», «Гасырлар авазы» исемле басмалар белән беррәттән, «Мирас» – «Чын мирас» – «Безнең мирас»ны тарихи материалларга, моңа кадәр аз билгеле булган ядкәрләргә урын бирелү ягыннан югары күтәрә. Җәмил Мөхәммәтшин хезмәтен, Казан ханлыгы тарихына караган язмаларны, Раиф Мәрданов белән Ирек Һадиевнең Татарстанның Казан арты авылларында сакланган борынгы кабер ташларын барлап язган хезмәтен уңай яктан бәяләгәннән соң,Төркиядә яшәүче фән докторы, профессор Исмәгыйль Төркуглының «Төрек-татар багланышлары» [8] дигән мәкаләсен « “Чын мирас”та 2012-2013 елларда басылган хезмәтләрдән минем өчен ачыш дәрәҗәсендә кабул ителгәне булды» [9: 30], – дип яза.

Язма авторы «Безнең мирас»та төрки-тугандаш халыкларның әдәби казанышлары,

сәнгати яктан гына түгел, эчтәлеге белән яңа сүз әйткән әсәрләре басылуны зур җылылык белән искә ала: «Чыңгыз Айтматовның Совет хакимияте елларында дөньяга чыгарырга шикләнебрәк йөргән күләмле әсәре – “Чыңгызханның ак болыты” [10] басыла башлады. Икеләтә сөенүемнең сәбәбе шулдыр: әдипнең кыргызча бер әсәре 1990 еллар башында “Ала too” журналында басылган иде. Шул вакытларда Урта Азиядә йөргәндә мин аны алып кайткан һәм мирасчыларга тапшырган идем. “Чыңгызханның ак болытын” укыганда әлеге журнал да һаман күз алдымда торган кебек булды…» [9: 31].

2013 елның декабреннән баш мөхәррир вазифасын әдип Ләбиб Лерон (Лемон Лерон улы Леронов) башкара. 2014 елның 30 гыйнварында «Татмедиа» матбугат һәм гәммави коммуникацияләр республика агентлыгы, «Татмедиа» ачык акционерлык җәмгыяте җитәкчеләре, журнал редакциясе хезмәткәрләре, күренекле галимнәр һәм әдипләр катнашында «Чын мирас» журналы: кичә, бүген, иртәгә» дип исемләнгән «түгәрәк өстәл» утырышы булып узды. Анда басманың исемен «Безнең мирас» итеп үзгәртү турындагы карар кабул ителеп, 2014 елның маеннан журнал «Безнең мирас» исеме белән нәшер ителә башлады [11: 9]. Ул тематика һәм проблематика ягыннан тагын да баеды һәм басмага яңадан-яңа рубрикалар өстәлде: «Тел күрке – сүз»; «Хәтер сагында»; «Хәтер сандыгы»; «Табигый мирас»; «Сәнгати мирас»; «Шаян мирас»; «Татар гаме»; «Төрки дөнья»; «Мирасворд»; «Безнең мирас» елъязмасы»; «Бер рәсем тарихы»; «Сүз һәм сурәт». Сәхифәләр белән бергә авторлар да артты, төрлеләнде, галимнәр, фән докторлары белән беррәттән, гади мәктәп укытучысының да язмасы дөнья күргән саннар бар. Иң мөһиме: журналда, фәнни-популяр өслүб барлыкка килеп, укучыга аңлаешлы тел белән язылган мирас язмалары басыла башлады,.

Татарстанда гына түгел, Россиянең төрле өлкәләрендә һәм чит илләрдәге милләттәшләребез хакында, аларның дини, рухи, әдәби вә сәнгати мирасын барлаган материал туплап бирү «Безнең мирас»ның янә тагын бер яңалыгы булды. Мәсәлән, Себер татарлары (Төмән, Тубыл), Пермь ягының Барда районы, Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районы, нижгар татарлары, Чувашия Республикасының Кыр Бикшеге авылы, Кытай Халык Республикасында яшәүче милләттәшләребез хакында язмалар әнә шундыйлардан.

2014 елда Казан төрки халыкларның мәдәни башкаласы дип игълан ителгәнлектән, журнал үзенең апрель (№4) санын тулаем төрки дөнья мәдәниятенә, сәнгатенә вә тарихына багышлап чыгарды. Шулай итеп, бүген дә уңышлы дәвам иткән «Төрки дөнья» сәхифәсе барлыкка килде. 2015 елда Бөек җиңүнең 70 еллыгы зурлап билгеләп үтелү уңаеннан, ел дәвамында «Безнең мирас»та «Җиңү – 70!» сәхифәсендә 54 язма дөнья күрде. Легендар милләттәшләребез, армия генералы Алексей Антонов, «Кара генерал» – Даян Мурзин хакындагы язмалар укучыда аеруча зур кызыксыну уятты.

Ул гына түгел, бердәм татар халкының аерым кавемнәре хакында кызыклы һәм киңкырлы материаллар бастыру да журналның күркәм традициясенә әверелде. Мәсәлән, «Безнең мирас»ның 2015 ел 3 саны, 2016 ел 7 саны тулысы белән керәшеннәргә багышланды.

Билгеле, бөек халыктан гына бөек мирас кала ала. Халкыбызның зурлыгын чирек гасыр дәвамында ай саен 2000шәр нөсхәдә дөнья күргән «Безнең мирас» журналы да раслый. 2012 елдан соң гына да йөзләгән онытылган исемнәр кире кайтты, тоныклана төшкәннәре яңартылды. Мәңгегә югалтылган кебек тоелган бибәһа кульязмалар, мәгълүм автор әйткәнчә, янмыйча, чормаларда, сандык төпләрендә үз сәгатен көтеп яткан һәм, көткәненә ирешеп, басманың төрле саннарында дөнья күргән «Котадгу белек» (Йосыф Баласагуни), «Сабирҗан агай: 1906 сәнәдә булган ачлыкны тасвир кыйлган роман» (Касыйм Бикколый), «Мәрьям», «Солдат йөрәге», «Сәнәкчеләр» (Зариф Мөэминов), «Каракүз» (Кәрим Тинчурин) кебек әсәрләр, Вафа Бәхтияровның Тукай турындагы тулы (цензура тарафыннан кыскартылмаган) истәлекләре, башта Муса Җәлилнеке дип исәпләнеп, ахыр чиктә Абдулла Алишныкы булып чыккан шигырьләр, эзләнүләр, табулар – барысы да журнал битләрендә урын алды һәм урын ала килә, халыктан бөртекләп җыелган җәүһәрләр, 120 битле басма булып, елга унике мәртәбә халыкның үзенә кайтарыла.

2016 ел башында журналда әдәбият, сәнгатьтә тирән эз калдырган күренекле шәхесләрнең соңгы сәгатьләрен, аларның бакыйлыкка озатылу мизгелләрен тасвирлый торган яңа «Очты дөнья читлегеннән…» сәхифәсе барлыкка килде. Үлемнәре белән дә укучыны яшәү матурлыгы һәм мәгънәсе

турында уйландырган Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Һади Такташ, Салих Сәйдәш, Дәрдемәнд һәм башкалар турындагы сәхифә укучыларның күңеленә хуш килде. Шуны да искәртергә кирәк: журнал чыга башлаганнан бирле, күпме гомер хатирәгә әверелгән, күпме шәхес, күпме әсәр мирас булып калган. Аларны да барлау, туплау, югалтырга юл куймау – шулай ук «Безнең мирас»ның изге бурычы. Мирасны барлаучы дәвамчыларны тәрбияләү һәм үстерү дә журналның гаять әһәмиятле юнәлешләреннән санала. Чирек гасыр эчендә ул, татар халкының көтеп алган басмасына әйләнеп, ун меңләп мирас ядкәрен дөньяга чыгарды.

«Безнең мирас» журналының 25 еллыгы 2016 елның көзендә мөхтәрәм зыялыларыбыз, галимнәр һәм әдипләр, җитәкчеләр катнашында, тантаналы рәвештә, зурлап билгеләп үтелде. Журналның тарихи, әдәби, мәдәни һәм рухи мирасыбызның әһәмиятен республика җитәкчелеге аңлап, басмага теләктәшлек күрсәтеп килә. Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе Фәрит Хәйрулла улы Мөхәммәтшин, Татарстанның беренче Президенты, «Яңарыш» фонды рәисе Минтимер Шәрип улы Шәймиев һәм башка мөхтәрәм зыялылар редакциягә котлау һәм рәхмәт сүзләрен ирештерде. Президент Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, «илебез һәм республикабыз күтәрелеш алган чорда татар халкының күпгасырлык мирасын җәмәгатьчелеккә җиткергән журналның бастырылуы зур вакыйга булды… Безнең уртак бурычыбыз – халкыбызның мирасын, телен һәм мәдәниятен киләчәк буыннар өчен саклап калу»[2].

Әйе, безнең уртак бурычыбыз – иң кадерле мирасыбыз булган Татар илен саклап калу. Шагыйрь әйтмешли, «яклыйк без аны, бергә күз карасыдай саклыйк. Дәвамчыларыбызга бөтен килеш тапшырыйк мирасыбызны:

*Тарих үзе гасыр ташларына*
*Һич җуелмас сүзләр уйгандыр:*
*Безнең мирас – газиз Татар иле,*
*Безнең мирас – гүзәл туган җир!*» [12: 3].

Шушы изге максатка йөз елдан артык тарихы булган матбугатыбызда үзенең кыйбласын булдырган киң тематик диапазонлы һәм дөньякүләм таралып абруй алган «Безнең мирас» айлык фәнни-популяр, әдәби-нәфис һәм документаль журналы хезмәт итә. Басма татар халкының тарихи хәтерен яңартып, иҗтимагый-милли үзаңын, милли хисләрен уятып, «бердәм милли байрак астында хәрәкәт иттерү» юнәлешендә җитди адымнар ясый.

**Әдәбият**


1. Ак юл синә, «Мирас»ыбыз! // Мирас. 1992. №1. Б. 3-5.
2. Мирасның нindие генә юк! // Мирас. 1992. №3. Б. 3-5.
3. Без нинди мираска мохтаҗ? // Мирас. 1992. №2. Б. 3-5.
4. *Мусин Ф.* Милләтебезгә фидакарь затлар кирәк! // Мирас. 1999. №2. Б. 4-22.
5. Без тарихта эзлебез // Мирас. 1991. № 1. Б. 4-5.
6. «Мирас» // Татар энциклопедиясе. Казан: Татар энциклопедиясе институты. Т.4: М-П. 2014. Б. 193.
7. *Ибраһимов И.* Мирасыбыз // Безнең мирас. 2012. 310. Б. 62-63.
8. *Төркуглы И.* XIX гасыр ахыры – XX йөз башы татар-төрек багланышлары // Чын мирас. 2013. №1. Б. 7-17; №2. Б. 5-19; №3. Б. 14-29.
9. *Хәмидуллин Л.* Уңышлы башламнар // Безнең мирас. 2016. №12. Б. 28-31.
10. *АйтматовЧ.* Чыңгызханның ак болыты // Безнең мирас. 2016. №8. Б. 68-73.
11. «Чын мирас» журналы: кичә, бүген, иртәгә // Чын мирас. 2014. №3. Б. 2-12.
12. *Лерон Л.* Безнең мирас – Татар иле! // Безнең мирас. 2016. №1. Б.3.


[2] Өзек «Безнең мирас» журналының 2016 ел 10 саны тышлык битенә урнаштырылган Татарстан Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнехановның редакциягә юллаган котлавыннан алынды.

# МЫ – НАРОД С НАСЛЕДИЕМ: К 25-ЛЕТИЮ ЖУРНАЛА «БЕЗНЕҢ МИРАС» («НАШЕ НАСЛЕДИЕ»)

**Фирдавес Забихуллович Зарифуллин,**
редакция журнала «Безнең мирас» («Наше наследие»),
Россия, 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2,
yanamiras@mail.ru.

**Марат Халилович Закиров,**
редакция журнала «Безнең мирас» («Наше наследие»),
Россия, 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2,
yanamiras@mail.ru.

В статье содержится материал, связанный с историей создания и функционирования журнала «Безнең мирас» («Наше наследие»). Первый номер журнала «Мирас» вышел в 1991 году. Главными редакторами издания были Ф.Мусин, А.Сахапов, И.Ибрагимов, Л.Лерон. В формировании научной концепции журнала приняли такие известные татарские ученые, писатели и общественные деятели, как А.Еники, Г.Баширов, М.Магдиев, М.Усманов, А.Каримуллин, М.Махмутов и др.: в статье дан обзор источников, в которых изложены их предложения по контенту журнала, ориентированного на сохранение и приумножение историко-документального наследия, других историко-культурных ценностей, являющихся национальным достоянием татарского народа, их активное и всестороннее использование. Выявлена динамика в создании рубрик журнала, определены ключевые тенденции в развитии издания на протяжении четверти века. Авторы статьи отмечают разносторонность журнала, который ориентирован как на широкий круг российских и зарубежных читателей, интересующихся татарской историей, так на узкий круг специалистов, которые имеют возможность размещать на страницах издания результаты фундаментальных комплексных исследований в области истории, литературы, языка и культуры татарского народа. Кратко охарактеризован вклад читателей, занимающихся исторической, краеведческой, педагогической работой, в создание научно-популярных статей для журнала общеисторической, патриотической тематики. В статье приведены статистические данные, позволяющие сформировать представление о настоящем издании «Безнең мирас» («Наше наследие»), планах на будущее.

**Ключевые слова**: история татарской журналистики, журнал «Безнең мирас» («Наше наследие»), история создания, рубрики, география распространения.